Рәдиф ҖАМАЛЕТДИНОВ:

# «Контингентыбызны югалтмадык»

**КФУНЫҢ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ ДИРЕКТОРЫ, ПРОФЕССОР РӘДИФ РИФКАТЬ УЛЫ ҖАМАЛЕТДИНОВ БЕЛӘН ИНСТИТУТНЫҢ БҮГЕНГЕСЕ ҺӘМ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕК.**

**– Рәдиф Рифкатович, Сез җитәкли торган институт озак еллар тупланган традицияләрне ни дәрәҗәдә уңышлы дәвам итә?**

– Әлбәттә, үз-үзебезгә бәя бирү катлаулырак. Миңа калса, бу турыда безнең белән турыдан-туры эшләүчеләр, йә булмаса, безнең кадрларны эшкә алучылар дөресрәк бәя бирер. Без мөмкин булган кадәр электән килгән традицияләрне саклап калырга, аларны үстерергә тырышабыз. Шулар белән беррәттән, яңалары да барлыкка килә. Бүгенге көндә институтта Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге, Л.Толстой исемендәге рус һәм чит ил филологиясе бүлеге, С.Сәйдәшев исемендәге югары сәнгать мәктәбе эшләп килә. Бүлекләр, нигездә, элеккеге КДУ һәм ТДГПУ факультетлары базасында оешты. Ике югары уку йортында да эчтәлекле, үзенчәлекле чаралар узып килә иде, әлеге традиция бүген дә уңышлы дәвам итә. Мәсәлән: а) югары уку йортларында укучы студентлар өчен татар теле буенча олимпиадалар моңарчы, нигездә, КДУ базасында оештырылды. Бу олимпиаданы әле дә үткәреп киләбез. Анда Татарстаннан да, Россиядән дә бик күп студент катнаша. Әйтик, быел республикабызның 10 югары уку йортыннан 130лап студент көч сынашты; б) бүгенге көндә татар теле һәм әдәбияты буенча өченче халыкара олимпиадага әзерләнәбез. Бу мәртәбәле олимпиада республикабыз Мәгариф һәм фән министрлыгы иницитивасы белән уздырыла; в) КДУда татар-инглиз, инглиз-татар телләренә тәрҗемә бәйгесе шактый еллардан бирле уздырыла иде. Бүген дә бу эш дәвам иттерелә; г) иҗат



юнәлешендә дә Казан университетында – «Шигъри Сабантуй», ТДГПУда «Илһам канатында» дигән бәйге үткәрелеп килә иде. Шушы көннәрдә генә бу конкурсларның йомгаклау турын уздырдык. Ике конкурста 700ләп бала катнашты; д) ТДГПУ базасында «Милли хәзинә» дип аталган студентлар фестивале уздырыла иде. Бу юнәлештәге эшчәнлек тә уңышлы гына бара; е) «Ана теле» дип аталган татар теленә өйрәтү программасын да элеккеге традицияләрне дәвам итү дип саныйм. Әлеге проектны тормышка ашыру өчен безнең институт базасында махсус лаборатория булдырылды. Бу – укытучыларыбызның дистә еллар дәвамында эшләп килгән проектның дәвамы. Хәтерлисездер: үз вакытында Флера Садриевна Сафиуллина, аның укучылары Америка, Германия һәм башка чит илләрдән килгән студентларга, укучыларга татар телен өйрәтте.

Фото: kpfu.ru

**– Институт бүгенге көндә нинди яңа проектлар белән мәшгуль?**

– Мин бу темага сөйләшүне Каюм Насыйри институты проектыннан башларга телим. Бу проект университет базасында республика Хөкүмәте ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Институтның төп максаты – Татарстаннан тыш, башка илләрдә һәм төбәкләрдә татар теле, әдәбияты һәм мәдәниятен пропагандалау. Әйтик, Казахстанда һәм башка төбәкләрдә татар телен өйрәнү өчен махсус курслар оештырылачак. Бу институт алдына тагын бер бурыч куябыз: бүгенге көндә татар теле, татар әдәбияты һәм мәдәният белән бәйле инновацион проектларны шушы институт аша шушы илләргә һәм төбәкләргә җиткерү.

Быел институтның Мәскәүдә һәм Казахстанда үзәкләре ачылачак. 2020 елга махсус челтәр барлыкка килер дип өметләнәбез. Әлеге үзәкләр белән дистанцион форматта эшләп, уку-укыту эшчәнлеген оештыра, аралаша алачакбыз.

Без республика Хөкүмәте белән берлектә өч телдә халыкара «Татарика» журналын чыгара башладык. Шулай ук «Ашыгыч лингвистик ярдәм» проекты турында да әйтеп китәсе килә. Дәүләт телләре буенча сораулары булган кешеләр, телефоннан шылтыратып, йә булмаса, электрон почта аша аларны безнең хезмәткәрләргә юллый алалар. Без аларга бик тиз арада җавап бирәчәкбез. Оператив рәвештә тәрҗемә эшен дә оештыра алабыз.

Чираттагы проект – сәләтле балалар белән эшли торган полилингваль уку йортлары челтәрен оештыру һәм алар белән системалы рәвештә эшләү. Бу челтәрдәге уку йортларында ана теле һәм әдәбияты, чит телләр (1 Европа һәм 1 көнчыгыш), информацион технологияләрне тирәнтен өйрәнү өстенлекле юнәлеш булып исәпләнә.

**– Рәдиф әфәнде, әңгәмәне институтның төп эшчәнлегенә кире кайтып дәвам итик әле. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты абитуриентлар өчен чыгарган буклетта: «Без синең телеңдә һәм дөнья телендә сөйләшәбез» дигән юллар бар. Бу сезнең эшчәнлегегезне бер җөмлә белән ачып бирә бит.**

– Әйе, бик дөрес. Бүгенге көндә яшьләр – прагматиклар. Алар чит телләр белән кызыксына. Ә безнең институт яшьләрнең шушы теләк-омтылышларын гамәлгә ашыру өчен бик отышлы, уңайлы мөмкинлекләр бирә. Кабул итү шартларына игътибар итсәгез, һәр юнәлеш һәм белгечлек буенча икенче белгечлек буларак чит тел куелган. Әйтик, Татар филологиясе факультетында 1995 елдан бирле, икенче белгечлек буларак, инглиз теле белгечлеге гамәлгә ашырыла. Шулай итеп, уку йортын тәмамлап чыккан вакытта, дипломда «Татар теле һәм инглиз теле укытучысы» дип языла. Классик филологиядә, рус филологиясендә дә шундый ук хәл. Бу музыка, рәсем сәнгате өлкәләрендәге белгечлекләргә дә кагыла. 2015 елда тагын хореография һәм чит тел дигән белгечлеккә дә балаларны кабул итәчәкбез.

**– Тагын нинди яңа белгечлекләр ачу көтелә?**

– Киләсе елда татар теле, әдәбияты һәм логопедия белгечлеге буенча кабул итү оештырылачак. Миңа калса, әлеге юнәлештәге белгечләрнең кирәклеге бәхәссез, чөнки әлегәчә бу юнәлештә татар логопедлары әзерләнмәде.

Югарыда әйтелгәннәрдән тыш, рус һәм чит ил филологиясе бүлегендә кызыклы гына белгечлекләр бар. Без быел рус филологиясе белгечлегенә өстәмә рәвештә славистика, шулай ук әдәби редакцияләү һәм тәнкыйть юнәлешләре буенча кабул итүне оештырдык. Шулай ук бу бүлектә магистратура программаларыннан кече яшьтәге балаларны өйрәтүдә мультилингваль технологияләр файдалану дигән яңа кызыклы белгечлек тәкъдим итәбез.

Тагын 2 яңалыгыбыз бар. 2015 елда югары сәнгать мәктәбендә магистратурага «Театраль педагогика» белгечле-

генә кабул итү оештырылачак, ә татар филологиясе һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлегендә, Татарстан Хөкүмәте матди ярдәме белән, синхрон тәрҗемәчеләр төркемен туплаячакбыз. Бу очракта без татар-рус, рус-татар тәрҗемәчеләре турында сүз алып барабыз.

**– Рәдиф әфәнде, менә Сез алдарак 1995 елдан бирле «Татар теле һәм инглиз теле укытучысы» дигән белгечлек буенча укыту турында әйтеп киттегез. Соңгы берничә елда татар теле бүген ихтыяҗ булган башка белгечлекләр белән дә берләштерелде бит әле. Моның максаты нидә иде?**

– Җәмгыятьтә төрле үзгәрешләр, телгә һәм башка милләтләргә мөнәсәбәтнең шулай ук төрле булуына карамастан, без үз контингентыбызны югалтмадык. Абитуриентларга берсеннән-берсе кызыклы, үзенчәлекле өстәмә белгечлекләр тәкъдим иттек. Әлбәттә, төп белгечлек – татар теле һәм әдәбияты. Без икенче белгечлек итеп төрек теле, гарәп теле, кытай теле, мәгълүмати технологияләр, балалар бакчалары белгечләре, хореография, рәсем сәнгате һ.б. буенча кабул итү оештырдык.

Мәгълүм булганча, бүгенге көндә республикада (башка төбәкләрдә дә) аз комплектлы мәктәпләр бар. Аларда бер генә белгечлек буенча тулы ставкага сәгатьләр җыю һәм зур хезмәт хакына өмет итү мөмкин түгел. Берничә юнәлештә әзерлеге булгач, яшьләргә үз урыннарын табу җиңелрәк.

**– Хәзерге вакытта институтта татар теле юнәлеше буенча белгечләр әзерләү өчен ничә студент кабул ителә?**

– 2014–2015 уку елына кабул итү турында сөйләсәк, институтка барлыгы 320дән артык бюджет урыны бирелгән иде. Шуның 52се – читтән торып уку бүлегенә, калганы көндезге бүлеккә. Көндезге бүлектә бер бюджет урынына – уннан артык, читтән торып уку бүлегенә биштән артык кеше дәгъва кылды. Ә татар филологиясенә килсәк, барысы 125 бала кабул иттек. Бу сан бүгенге көн өчен аз түгел.

2014 елда татар филологиясе юнәлешендә магистратурага «әдәби тәнкыйть һәм редакцияләү, нәшер итү» дигән программа буенча кабул итү дә оештырдык.

Магистрлык программаларына килгәндә, быел төрки телләр һәм мәдәниятара бәйләнешләр, татар телен һәм әдәбиятын укытуның яңа технологияләре, музыка һәм хореография өлкәсендәге менеджмент, дизайнда компьютер технологияләре, рус теле һәм әдәбиятын полиэтник шартларда укыту, «эшлекле инглиз теле» программалары буенча студентлар кабул ителде.

**– Бүгенге көндә институт алдында хәл итәсе нинди актуаль проблемалар бар?**

– Хәл итәсе мәсьәләләр шактый. Шулай да иң мөһим мәсьәлә дип институтыбызның йөзен, укытучы-галимнәребезне саклап калу, потенциалыбызны югалтмауны күрәм. Күз алдына китерегез: элек 100 студент белән 15 укытучы эшләгән булса (безнең элек нормативлар буенча якынча шуңа чыга иде), бүгенге көндә 100 студент белән 10 укытучы гына эшләргә тиеш. Без кемгә өстенлек бирергә тиеш? Озак еллар дәвамында эшләгән, исеме танылган фән докторлары, профессор, академикларгамы? Йә булмаса, үсеп килә торган, кандидатлык диссертациясе яклаган, докторлык диссертациясе өстендә эшләүче яшь галимнәргәме? Без менә шундый дилемма алдында калдык. «Алтын урталык»ны табу буенча бик озак эзләнүләр барды. Кафедра мөдирләре, бүлек җитәкчеләре, урынбасарларым, аксакалларыбыз белән бергә тиешле карарлар кабул иттек. Бәлки югалтуларыбыз да булгандыр. Мин коллективка бүгенге көндә бик рәхмәтлемен, аңлашып эшлибез. Без өлкән яшьтәге укытучыларга йөкләмәне күпмедер күләмдә киметтек. Аларга, нигездә, консультация бирү, аспирантлар белән җитәкчелек эшен тапшырдык. Ә инде яшь укытучыларыбызга әлеге танылган галимнәр янәшәсендә үз эшчәнлеген дәвам итәргә мөмкинлек һәм шартлар тудырдык...

**Әңгәмәдәш – Римма ГАТИНА.**